**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Сәвәләй торак пунктында гражданнар җыены карары**

10.11.2020 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегенең Сәвәләй торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар һәм ялгыз өлкәннәрдән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегенең Сәвәләй торак пунктында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2021 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга:

- Котовский урамыннан чишмә башына кадәр юл салу, чишмә башында тукталыш ясау;
- Котовский урамы территориясен яктырту,
- зират янын төзекләндерү һәм чүп-чар мәйданчыгы ясау,
-чишмәне ремонтлау һәм тирә-юнен төзекләндерү,
-Ленин һәм Яшьләр урамнары буйлап юлның бер өлешен вак таш белән түшәү,
- Котовский урамыннан зиратка кадәр юл, зират янында тукталыш ясау,
-сүүткәргечне алмаштыру һәм 2 янгын гидранты урнаштыру.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Сәвәләй авыл җирлеге башлыгы П.С.Уразайкин